| | |
| --- | --- |
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| ЧЕРЕМШАНСКИЙ | ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ |
| МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН | **ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ** |
| **СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО** | **СОВЕТЫ** |
| **СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | |
| Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109 | Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы,423109 |

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№25** **16 июнь 2021**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 декабрендәге 80 номерлы «Яңа Кади авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Яңа Кади авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 778 номерлы указын, «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» һәм коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 декабрендәге 80 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында, шулай ук Яңа Кади авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә, 7 бүлекнең «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә әлеге алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешкә кадәрге соңгы өч ел өчен гомуми керемennән артып китсә һәм алыш-биреш ясалган чараларны алу чыганаклары турында белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе М.М.Әминов